**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Об утверждении Дополнительного соглашения от 1 июля 2021 г. № 1 к Соглашению от 14 декабря 2020 г. № 01-01-06/06-1022 о предоставлении бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета бюджетного кредита для погашения бюджетных кредитов на пополнение остатков средств на счетах бюджетов субъектов Российской Федерации

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 сентября 2021 года

## Статья 1

Утвердить Дополнительное соглашение от 1 июля 2021 г. № 1 к Соглашению от 14 декабря 2020 г. № 01-01-06/06-1022 о предоставлении бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета бюджетного кредита для погашения бюджетных кредитов на пополнение остатков средств на счетах бюджетов субъектов Российской Федерации, заключенное между Министерством финансов Российской Федерации и Кабинетом Министров Республики Татарстан в рамках проведенной Правительством Российской Федерации в соответствии со статьей 3 Федерального закона от 28 июня 2021 года № 228-ФЗ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Российской Федерации и о приостановлении действия отдельных положений Бюджетного кодекса Российской Федерации» и постановлением Правительства Российской Федерации от 28 июня 2021 года № 1029 «Об утверждении Правил проведения в 2021 году реструктуризации обязательств (задолженности) субъектов Российской Федерации перед Российской Федерацией по бюджетным кредитам» реструктуризации обязательств (задолженности) Республики Татарстан перед Российской Федерацией по бюджетному кредиту в пределах остатков не погашенной на дату реструктуризации задолженности по бюджетному кредиту, предоставленному Республике Татарстан для погашения бюджетных кредитов на пополнение остатков средств на счетах бюджетов субъектов Российской Федерации, на сумму 2 063 527 000 рублей, согласно приложению к настоящему Закону.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
30 сентября 2021 года
№ 67-ЗРТ

Приложение
к Закону Республики Татарстан
«Об утверждении Дополнительного соглашения от 1 июля 2021 г. № 1
к Соглашению от 14 декабря 2020 г. № 01-01-06/06-1022 о предоставлении
бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета
бюджетного кредита для погашения бюджетных кредитов
на пополнение остатков средств на счетах бюджетов
субъектов Российской Федерации»

# ДОПОЛНИТЕЛЬНОЕ СОГЛАШЕНИЕ № 1

## к Соглашению от 14 декабря 2020 г. № 01-01-06/06-1022 о предоставлении бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета бюджетного кредита для погашения бюджетных кредитов на пополнение остатков средств на счетах бюджетов субъектов Российской Федерации

г. Москва «1» июля 2021 г.

Министерство финансов Российской Федерации, именуемое в дальнейшем Кредитором, в лице первого заместителя Министра финансов Российской Федерации Л.В. Горнина, действующего на основании приказа Министерства финансов Российской Федерации от 10 декабря 2020 г. № 1088, с одной стороны, и Кабинет Министров Республики Татарстан, именуемый в дальнейшем Заемщиком, в лице Премьер-министра Республики Татарстан А.В. Песошина, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, Бюджетного кодекса Республики Татарстан, Закона Республики Татарстан от 6 апреля 2005 г. № 64-ЗРТ «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан» и распоряжения Президента Республики Татарстан от 6 мая 2017 г. № 273, с другой стороны, далее именуемые Сторонами, в соответствии с частью 2 статьи 3 Федерального закона от 28 июня 2021 г. № 228-ФЗ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Российской Федерации и о приостановлении действия отдельных положений Бюджетного кодекса Российской Федерации» и постановлением Правительства Российской Федерации от 28 июня 2021 г. № 1029 «Об утверждении Правил проведения в 2021 году реструктуризации обязательств (задолженности) субъектов Российской Федерации перед Российской Федерацией по бюджетным кредитам» (далее – Правила) заключили настоящее Дополнительное соглашение о нижеследующем.

1. Стороны подтверждают, что на дату заключения настоящего Дополнительного соглашения обязательства (задолженность) Заемщика по бюджетному кредиту, предоставленному бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета для погашения бюджетных кредитов на пополнение остатков средств на счетах бюджетов субъектов Российской Федерации в соответствии с Соглашением от 14 декабря 2020 г. № 01-01-06/06-1022 (далее – Соглашение), составляют 2 063 527 000 (два миллиарда шестьдесят три миллиона пятьсот двадцать семь тысяч) рублей, в том числе:

а) по основному долгу – 2 063 527 000 (два миллиарда шестьдесят три миллиона пятьсот двадцать семь тысяч) рублей;

б) по начисленным за фактический срок пользования бюджетным кредитом на дату реструктуризации задолженности процентам – 0 (ноль) рублей.

2. С даты вступления в силу настоящего Дополнительного соглашения обязательства (задолженность) Заемщика, указанные в пункте 1 настоящего Дополнительного соглашения, консолидируются и представляют собой реструктурированную задолженность.

Погашение реструктурированной задолженности осуществляется Заемщиком в период с 2021 года по 2029 год включительно со следующими сроками погашения: в 2021 - 2024 годах ежегодно в размере 5 процентов суммы задолженности, в 2025 - 2029 годах ежегодно равными долями от остатка суммы задолженности в соответствии с графиком согласно приложению к настоящему Дополнительному соглашению, который является неотъемлемой частью настоящего Дополнительного соглашения (далее-график), - с возможностью ее досрочного погашения.

Погашение Заемщиком реструктурированной задолженности осуществляется ежегодно, не позднее 1 декабря соответствующего года.

3. На остаток реструктурированной задолженности, начиная со 2 июля 2021 года по день исполнения (включительно) в полном объеме обязательств по погашению реструктурированной задолженности, начисляется плата в размере 0,1 процента годовых (далее – проценты за рассрочку).

Уплата процентов за рассрочку в 2021-2029 годах осуществляется одновременно с погашением реструктурированной задолженности ежегодно, не позднее 1 декабря соответствующего года.

В случае досрочного погашения реструктурированной задолженности уплата процентов за рассрочку осуществляется одновременно с досрочным погашением. При этом проценты за рассрочку за год, в котором производится досрочное погашение, не пересчитываются.

При уплате процентов за рассрочку в поле 104 расчетного документа Заемщик указывает соответствующий код бюджетной классификации.

4. Реструктуризация задолженности по бюджетному кредиту, указанному в пункте 1 настоящего Дополнительного соглашения, проводится при условии принятия Заемщиком следующих обязательств:

а) направление в 2021 - 2024 годах средств бюджета субъекта Российской Федерации, высвобождаемых в 2021 году в результате снижения объема погашения задолженности по бюджетным кредитам, на осуществление субъектом Российской Федерации бюджетных инвестиций в объекты инфраструктуры в целях реализации новых инвестиционных проектов, определяемых в соответствии с частью 3 статьи 3 Федерального закона от 28 июня 2021 г. № 228-ФЗ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Российской Федерации и о приостановлении действия отдельных положений Бюджетного кодекса Российской Федерации» (далее – новые инвестиционные проекты) в порядке, предусмотренном Правительством Российской Федерации.

Объем высвобождаемых средств бюджета субъекта Российской

Федерации, подлежащих направлению на цели, предусмотренные в абзаце первом настоящего подпункта, рассчитывается как разница между объемом погашения реструктурированной задолженности, определяемым в соответствии с графиком погашения задолженности по бюджетному кредиту, уплаты процентов за пользование бюджетным кредитом, являющимся приложением к Соглашению, и объемом погашения реструктурированной задолженности, определяемым в соответствии с абзацем первым пункта 8 Правил и абзацем вторым пункта 2 настоящего Дополнительного соглашения, в 2021 году, и составляет 1 960 350 650 (один миллиард девятьсот шестьдесят миллионов триста пятьдесят тысяч шестьсот пятьдесят) рублей;

б) утверждение настоящего Дополнительного соглашения законом субъекта Российской Федерации (за исключением закона о бюджете субъекта Российской Федерации на очередной финансовый год и плановый период) и в 6-месячный срок со дня его подписания представление копии закона субъекта Российской Федерации Кредитору;

в) представление ежегодно, в течение 14 рабочих дней после утверждения закона о бюджете субъекта Российской Федерации на очередной финансовый год и плановый период, Кредитору выписки из закона о бюджете субъекта Российской Федерации на очередной финансовый год и плановый период с указанием суммы средств, направляемых на погашение реструктурированной задолженности и (или) уплату процентов за рассрочку. Указанная выписка из закона о бюджете субъекта Российской Федерации на 2021 год и на плановый период 2022 и 2023 годов должна быть представлена не позднее 30 декабря 2021 года;

г) представление Кредитору ежегодно, не позднее 25 февраля года, следующего за отчетным, до полного погашения реструктурированной задолженности информации о выполнении условий реструктуризации, предусмотренных подпунктами «а» - «в» настоящего пункта.

5. В случае нарушения Заемщиком графика Заемщик уплачивает пени в размере 1/300 ключевой ставки, установленной Центральным банком Российской Федерации на дату наступления сроков исполнения обязательств, от общего объема реструктурированной задолженности по бюджетным кредитам за каждый день просрочки исполнения обязательства.

В случае если по истечении 14 рабочих дней со дня наступления срока, установленного графиком, Заемщиком не осуществлены погашение реструктурированной задолженности и (или) уплата процентов за рассрочку, непогашенная реструктурированная задолженность, а также начисленные проценты за рассрочку, предусмотренные соответствующим графиком на конкретную дату, подлежат досрочному единовременному погашению Заемщиком. Одновременно подлежат уплате пени за указанный период.

При оценке исполнения Заемщиком обязательств по итогам 2024 года, предусмотренных подпунктом «а» пункта 10 Правил и подпунктом «а» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения, средства бюджета субъекта Российской Федерации, подлежавшие направлению субъектом Российской Федерации в отчетном году на цели, предусмотренные подпунктом «а» пункта

10 Правил и подпунктом «а» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения, в части направления высвобождаемых средств на осуществление субъектом Российской Федерации бюджетных инвестиций в объекты инфраструктуры в целях реализации новых инвестиционных проектов, определяются исходя из объема средств бюджета субъекта Российской Федерации, направленных на указанные цели в 2021-2024 годах.

При неисполнении Заемщиком обязательств по итогам 2021 - 2024 годов, предусмотренных подпунктом «а» пункта 10 Правил и подпунктом «а» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения, Заемщик погашает реструктурированную задолженность и проценты за рассрочку согласно графику в 2025 году, а также досрочно, в 2025-2027 годах, ежегодно равными долями, в срок, установленный графиком, предусматривающим досрочное погашение задолженности, погашает задолженность в объеме высвобождаемых средств, подлежавших направлению на осуществление субъектом Российской Федерации бюджетных инвестиций в объекты инфраструктуры в целях реализации новых инвестиционных проектов.

При оценке исполнения Заемщиком обязательств по итогам 2021 - 2024 годов, предусмотренных подпунктом «а» пункта 10 Правил и подпунктом «а» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения, объем реструктурированной задолженности по бюджетным кредитам, подлежащий досрочному погашению в соответствии с абзацем четвертым настоящего пункта, снижается на сумму фактически произведенных в 2021 - 2024 годах расходов в пределах объема высвобождаемых средств, предусмотренных подпунктом «а» пункта 10 Правил и подпунктом «а» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения, а также на сумму средств, направленных субъектом Российской Федерации на погашение в 2022-2024 годах реструктурированной задолженности по бюджетным кредитам.

При нарушении Заемщиком положений подпункта «б» пункта 10 Правил и подпункта «б» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения непогашенная реструктурированная задолженность, а также начисленные проценты за рассрочку подлежат досрочному единовременному погашению Заемщиком.

Неисполнение Заемщиком обязательств, предусмотренных подпунктами «в» и «е» пункта 10 Правил и подпунктами «в»-«г» пункта 4 настоящего Дополнительного соглашения, влечет применение высшим должностным лицом субъекта Российской Федерации (руководителем высшего исполнительного органа государственной власти субъекта Российской Федерации) мер дисциплинарной ответственности в соответствии с законодательством Российской Федерации к должностным лицам органов государственной власти субъекта Российской Федерации, чьи действия (бездействие) привели к нарушению указанных обязательств.

Кредитор применяет предусмотренные законодательством Российской Федерации меры по взысканию с Заемщика просроченной задолженности по бюджетным кредитам и (или) пени за неисполнение обязательств по погашению реструктурированной задолженности по бюджетным кредитам.

6. Остальные условия Соглашения, не затронутые настоящим Дополнительным соглашением и не противоречащие ему, остаются неизменными, и Стороны подтверждают по ним свои обязательства.

7. Настоящее Дополнительное соглашение является неотъемлемой частью Соглашения и вступает в силу со дня его подписания Сторонами.

8. Настоящее Дополнительное соглашение составлено на 6 листах, включая приложение, в двух экземплярах, имеющих равную юридическую силу, по одному для каждой из Сторон.

**Место нахождения и адрес Сторон**

**Кредитор** - Министерство финансов Российской Федерации, ул. Ильинка, 9, г. Москва, 109097.

**Заемщик** - Кабинет Министров Республики Татарстан, пл. Свободы, 1, г. Казань, 420060.

**Подписи Сторон**

| **От Кредитора** | **От Заемщика** |
| --- | --- |
| Первый заместитель Министра финансов Российской Федерации | Премьер-министр Республики Татарстан |
| Л.В. Горнин | А.В. Песошин |
| _______________ (подпись) | _______________ (подпись) |
| М.П. | М.П. |

Приложение к Дополнительному соглашению
от «1» июля 2021 г. № 1
к Соглашению от 14 декабря 2020 г. № 01-01-06/06-1022
о предоставлении бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета бюджетного кредита для погашения бюджетных кредитов на пополнение остатков средств на счетах бюджетов субъектов Российской Федерации

# График
погашения реструктурированной задолженности и уплаты процентов за рассрочку

| Срок возврата | | Реструктурированная задолженность (рублей) | Сумма возврата реструктурированной задолженности (рублей) | Проценты за рассрочку (рублей) | Итого к уплате (рублей) |
|---|---|---|---|---|---|
| 2021 г. | 30.11.2021 | 2 063 527 000,00 | 103 176 350,00 | 1 025 827,32 | 104 202 177,32 |
| 2022 г. | 30.11.2022 | 1 960 350 650,00 | 103 176 350,00 | 1 951 587,73 | 105 127 937,73 |
| 2023 г. | 30.11.2023 | 1 857 174 300,00 | 103 176 350,00 | 1 848 411,38 | 105 024 761,38 |
| 2024 г. | 29.11.2024 | 1 753 997 950,00 | 103 176 350,00 | 1 744 977,07 | 104 921 327,07 |
| 2025 г. | 28.11.2025 | 1 650 821 600,00 | 330 164 320,00 | 1 620 971,13 | 331 785 291,13 |
| 2026 г. | 30.11.2026 | 1 320 657 280,00 | 330 164 320,00 | 1 292 615,93 | 331 456 935,93 |
| 2027 г. | 30.11.2027 | 990 492 960,00 | 330 164 320,00 | 962 451,61 | 331 126 771,61 |
| 2028 г. | 30.11.2028 | 660 328 640,00 | 330 164 320,00 | 632 363,91 | 330 796 683,91 |
| 2029 г. | 30.11.2029 | 330 164 320,00 | 330 164 320,00 | 302 122,97 | 330 466 442,97 |
| Итого | x | x | 2 063 527 000,00 | 11 381 329,05 | 2 074 908 329,05 |

**Подписи Сторон**

| **От Кредитора** | **От Заемщика** |
|---|---|
| Первый заместитель Министра финансов Российской Федерации | Премьер-министр Республики Татарстан |
| Л.В. Горнин | А.В. Песошин |
| (подпись) | (подпись) |
| М.П. | М.П. |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы өстәмә килешүне раслау хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен Татарстан Республикасына бирелгән бюджет кредиты буенча бурычның реструктурлаштыру датасына түләнеп бетмәгән калдыклары чикләрендә Татарстан Республикасының бюджет кредиты буенча Россия Федерациясе каршындагы йөкләмәләрен (бурычларын) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы һәм «2021 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 июнендәге 1029 номерлы карары нигезендә үткәрелгән реструктурлаштыру кысаларында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы 2 063 527 000 сумлык Өстәмә килешүне әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 67-ТРЗ

«Россия Федерациясе субъектлары
бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга
бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү
турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы
килешүгә 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы
өстәмә килешүне раслау хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә 1 номерлы

# ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2021 елның «1» июле

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2020 елның 10 декабрендәге 1088 номерлы боерыгы нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеше һәм «2021 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру кагыйдәләрен раслау турында» (алга таба – Кагыйдәләр) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 июнендәге 1029 номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешү төзеделәр.

1. Яклар әлеге Өстәмә килешү төзелгән датага Заемщикның 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы Килешү (алга таба – Килешү) нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән бюджет кредиты буенча йөкләмәсе (бурычлары) 2 063 527 000 (ике миллиард алтмыш өч миллион биш йөз егерме җиде мең) сум дип раслыйлар, шул исәптән:

а) төп бурыч буенча – 2 063 527 000 (ике миллиард алтмыш өч миллион биш йөз егерме җиде мең) сум;

б) бурычны реструктурлаштыру датасына бюджет кредитыннан фактта файдалану срогы өчен исәпләнгән процентлар буенча – 0 (ноль) сум.

2. Әлеге Өстәмә килешү үз көченә кергән датадан Заемщикның әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән йөкләмәләре (бурычлары) берләштерелә һәм реструктурлаштырылган бурыч булып тора.

Реструктурлаштырылган бурычны каплау Заемщик тарафыннан 2021 елдан 2029 елга кадәр (2029 елны да кертеп) түбәндәге түләү срокларында башкарыла: 2021 – 2024 елларда ел саен бурыч суммасының 5 проценты күләмендә, 2025 – 2029 елларда, вакытыннан алда түләп бетерү мөмкинлеге белән, калган бурыч суммасын ел саен тигез өлешләр белән әлеге Өстәмә килешүгә кушымтада бирелгән график нигезендә, график Өстәмә килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора (алга таба – график).

Реструктурлаштырылган бурыч Заемщик тарафыннан ел саен, тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнә.

3. Реструктурлаштырылган бурычның калган өлешенә, 2021 елның 2 июленнән алып реструктурлаштырылган бурычны түләү йөкләмәсен тулы күләмдә үтәү көненә кадәр, еллык 0,1 процент күләмендә түләү (алга таба – кичектереп түләгән өчен процентлар) исәпләнә.

2021 – 2029 елларда кичектереп түләгән өчен процентларны түләү ел саен, тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, реструктурлаштырылган бурычны түләү белән бергә гамәлгә ашырыла.

Реструктурлаштырылган бурычны вакытыннан алда түләп бетергән очракта, кичектереп түләгән өчен процентларны түләү вакытыннан алда түләп бетерү белән бергә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта вакытыннан алда түләү башкарыла торган ел өчен процентлар яңадан саналмый.

Кичектереп түләгән өчен процентларны түләгәндә Заемщик исәп-хисап документының 104 юлында бюджет классификациясенең тиешле кодын күрсәтә.

4. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредиты буенча бурычларны реструктурлаштыру Заемщик тарафыннан түбәндәге йөкләмәләрне кабул итү шарты белән үткәрелә:

а) Россия Федерациясе субъекты бюджетының 2021 елда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә вакытлыча тотылмый торган акчаларын 2021 – 2024 елларда «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясындагы 3 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын (алга таба – яңа инвестиция проектлары) гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан бюджет инвестицияләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан каралган тәртиптә инфраструктура объектларында гамәлгә ашыруга юллау.

Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан вакытлыча тотылмый торган,

әлеге пунктчаның беренче абзацында каралган максатларга юнәлдерелергә тиешле акчалар күләме 2021 елда бюджет кредиты буенча бурычны түләү графигы нигезендә билгеләнә торган реструктурлаштырылган бурычны түләү, бюджет кредитыннан файдаланган өчен Килешүгә кушымта итеп бирелгән процентларны түләү күләме һәм Кагыйдәләрнең 8 пунктындагы беренче абзацы һәм әлеге Өстәмә килешүнең 2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә билгеләнә торган реструктурлаштырылган бурычны түләү күләме арасындагы аерма буларак исәпләнә һәм 1 960 350 650 (бер миллиард тугыз йөз алтмыш миллион өч йөз илле мең алты йөз илле) сум тәшкил итә;

б) әлеге Өстәмә килешүне Россия Федерациясе субъекты законы белән раслау (чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында законнан тыш) һәм аңа кул куелган көннән алып 6 ай эчендә Россия Федерациясе субъекты законы күчермәсен Кредиторга тапшыру;

в) чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында закон расланганнан соң, ел саен, 14 эш көне эчендә Кредиторга, реструктурлаштырылган бурычны түләүгә һәм (яисә) кичектереп түләгән өчен процентларны түләүгә юнәлдерелә торган акчалар суммасын күрсәтеп, чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан өземтә бирергә. 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан күрсәтелгән өземтә 2021 елның 30 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш;

г) реструктурлаштыруның әлеге пунктның «а»–«в» пунктчаларында каралган шартларын үтәү турында мәгълүматны ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 25 февраленнән дә соңга калмыйча, реструктурлаштырылган бурычны тулысынча каплап бетергәнче Кредиторга тапшыру.

5. Заемщик тарафыннан график бозылган очракта, Заемщик йөкләмәләрне үтәү срогы башланган датага Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пеня түли, пеня йөкләмәләрне үтәү кичектерелгән һәр көн өчен бюджет кредитлары буенча реструктурлаштырылган бурычның гомуми күләменнән чыгып исәпләнә.

Реструктурлаштырылган бурыч һәм (яки) кичектереп түләгән өчен процентлар Графикта билгеләнгән срок җиткәннән соң 14 эш көне узганчы Заемщик тарафыннан түләнмәгән очракта, капланмаган реструктурлаштырылган бурыч һәм шулай ук кичектереп түләгән өчен тиешле графикта конкрет датага саналган процентлар Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиеш. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пеня да түләнергә тиеш.

Заемщик тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрнең 2024 ел йомгаклары буенча үтәлешен бәяләгәндә, хисап елында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган максатларга юнәлдерелергә тиешле Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары, тотылмый калган акчаларны яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан

инфраструктура объектларында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрү өлешендә, күрсәтелгән максатларга 2021 – 2024 елларда юнәлдерелгән Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары күләменнән чыгып билгеләнә.

Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләр 2021 – 2024 ел йомгаклары буенча Заемщик тарафыннан үтәлмәгән очракта, Заемщик график нигезендә 2025 елда реструктурлаштырылган бурычны һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түли, шулай ук вакытыннан алда, 2025 – 2027 елларда, ел саен тигез күләмнәрдә, бурычны алдан каплауны күздә тоткан графикта билгеләнгән срокларда, яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиешле тотылмый калган акчалар күләмендә бурычны түли.

Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрнең 2021 – 2024 ел йомгаклары буенча Заемщик тарафыннан үтәлешен бәяләгәндә, бюджет кредитлары буенча әлеге пунктның дүртенче абзацы нигезендә вакытыннан алда түләнергә тиешле реструктурлаштырылган бурыч күләме, Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «а» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында каралган тотылмый калган акчалар күләме чикләрендә, 2021 – 2024 елларда фактта тотылган чыгымнар суммасына, шулай ук 2022 – 2024 елларда Россия Федерациясе субъекты тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктурлаштырылган бурычны түләүгә җибәрелгән акчалар суммасына кими.

Заемщик тарафыннан Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «б» пунктчасында һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «б» пунктчасында каралган нигезләмәләр бозылган очракта, капланмаган реструктурлаштырылган бурыч, шулай ук кичектереп түләгән өчен исәпләнгән процентлар Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы түләнергә тиеш.

Заемщикның Кагыйдәләрнең 10 пунктындагы «в» һәм «е» пунктчаларын һәм әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «в»-«г» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының гамәлләре (гамәл кылмаулары) күрсәтелгән йөкләмәләрне бозуга китергән вазыйфаи затларына карата Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Кредитор Заемщиктан бюджет кредитлары буенча үз вакытында түләнмәгән бурычларны һәм (яисә) бюджет кредитлары буенча реструктурлаштырылган бурычны каплау буенча үтәлмәгән йөкләмәләр өчен пеня түләттерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны куллана.

6. Килешүнең әлеге Өстәмә килешүдә каралмаган, аңа каршы килми торган калган шартлары үзгәрми һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

7. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге Өстәмә килешү, кушымтаны да кертеп, һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә, 6 биттә төзелде.

**Якларның урнашу урыннары һәм адреслары**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка урамы, 9 йорт, Мәскәү шәһәре, 109097.
**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1 йорт, Казан шәһәре, 420060.

**Якларның имзалары**

| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
| --- | --- |
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| Л.В. Горнин | А.В. Песошин |
| ____________________<br>(имза) | ____________________<br>(имза) |
| **М.У.** | **М.У.** |

Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында
калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын
каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредиты бирү турында
2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022
номерлы килешүгә 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы
Өстәмә килешүгә
кушымта

Реструктурлаштырылган бурычны каплау һәм кичектереп түләгән өчен процентларны түләү графигы

| Кайтару срогы | | Реструктурлаштырылган бурыч (сум) | Реструктурлаштырылган бурычны кайтару суммасы (сум) | Кичектереп түләгән өчен процентлар (сум) | Түләү (барлыгы) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| 2021 ел | 30.11.2021 | 2 063 527 000,00 | 103 176 350,00 | 1 025 827,32 | 104 202 177,32 |
| 2022 ел | 30.11.2022 | 1 960 350 650,00 | 103 176 350,00 | 1 951 587,73 | 105 127 937,73 |
| 2023 ел | 30.11.2023 | 1 857 174 300,00 | 103 176 350,00 | 1 848 411,38 | 105 024 761,38 |
| 2024 ел | 29.11.2024 | 1 753 997 950,00 | 103 176 350,00 | 1 744 977,07 | 104 921 327,07 |
| 2025 ел | 28.11.2025 | 1 650 821 600,00 | 330 164 320,00 | 1 620 971,13 | 331 785 291,13 |
| 2026 ел | 30.11.2026 | 1 320 657 280,00 | 330 164 320,00 | 1 292 615,93 | 331 456 935,93 |
| 2027 ел | 30.11.2027 | 990 492 960,00 | 330 164 320,00 | 962 451,61 | 331 126 771,61 |
| 2028 ел | 30.11.2028 | 660 328 640,00 | 330 164 320,00 | 632 363,91 | 330 796 683,91 |
| 2029 ел | 30.11.2029 | 330 164 320,00 | 330 164 320,00 | 302 122,97 | 330 466 442,97 |
| **Барлыгы** | **x** | **x** | **2 063 527 000,00** | **11 381 329,05** | **2 074 908 329,05** |

**Якларның имзалары**

**Кредитордан:**

Россия Федерациясе
Финанс министрының
беренче урынбасары

Л.В. Горнин

_________________
(имза)

**М.У.**

**Заемщиктан:**

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

А.В. Песошин

_________________
(имза)

**М.У.**